ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТҮБӘН КАМА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№18 24 гыйнвар, 2018 ел

**Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804нче карары белән расланган, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендә гамәлгә кергән 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Төзелеш алып бару һәм аны файдалануга тапшыру өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында” 2017 елның 27 сентябрендә гамәлгә кергән 729нчы номерлы карары, “Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында административ регламентларны эшкәртү һәм раслау тәртибен кабул итү турында” 2010 елның 18 ноябрендә гамәлгә кергән 1491нче номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804нче карары белән расланган, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентына үзгәрешләрне кабул итәргә (11нче номерлы кушымта).

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм архитектура идарәсенә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Төзелеш алып бару һәм аны файдалануга тапшыру өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында” 2017 елның 27 сентябрендә гамәлгә кергән карары үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эш бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Гамәлдәге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

А.Г.Сәйфетдинов

Кушымта
Расланган
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2013 елның 28 маенда кабул ителгән
804нче карары белән

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 маенда кабул ителгән 804нче карары белән расланган, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» баганасының 2.5нче пунктын түбәндәге эчтәлектәге сүзләр белән тулыландырырга:

« Гамәлдәге пунктта күрсәтелгән документларның бары тик электрон формада гына җибәрелергә тиешле очраклары:
әгәр капиталь төзелеш объектының проект документациясе экспертизасыннан уңай нәтиҗә (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 48нче маддәсе 12.1. өлешендә каралганча, төзелешнең аерым этапларына бәйле), Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы маддәсе 3.4. өлеше нигезендә каралганча, проект документациясе экспертизасыннан уңай нәтиҗә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы маддәсе 6нчы өлеше нигезендә каралганча, проект документациясе экспертизасыннан уңай нәтиҗәләр электрон формада тәкъдим ителгән булса; әгәр капиталь төзелеш объектының һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре проект документациясе, һәм шулай ук дәүләт экспертизасын үткәрү өчен кирәкле булган башка документлар электрон формада тәкъдим ителгән булса».